

“Татар кызы” бәйгесе – матурлык, сәләт һәм милли традицияләр бәйрәме. Татар кызларынын кvркәм сыйфатларын, халкыбызнын гореф-гадәтләрен, телен, мәдәниятен саклау һәм vстерv, сәләтен кvрсәтv - бәйгенен топ максаты булып тора.
Белгәнебезчә, 17 сентябрь конне Үзбәкстаннын башкаласы Ташкент шәһәренен «Туркистон» сәнгать сараенда “Татар кызы” Халыкара бәйгесенен грандиоз тамашасы vткән. Ике атна дәвамында Россиянен 9 тобәгеннән һәм 4 чит илдән килгән катнашучы белем бирv, мәдәни һәм кvнел ачу чараларында булганнар. Әлбәттә, кvпчелек вакытларын кызлар вокал, бию һәм нәфис сvз буенча дәресләрдә vткәргән. Кvпме коткән, никадәр әзерләнгән вакыйга берничә сәгать эчендә уза да китә, ләкин йорәкләрдә мәнге онытылмаслык хатирә, хисләр калдыра! Һәм, ниһаять, без әлеге тырышлыкларнын нәтижәсен кvрдек.
Бәйгенен жинvчесе, ГРАН-ПРИ иясе, безнен кvршебез Пенза олкәсеннән Альбина Медведева. Ихластан Мордовия татарлары Альбинаны олы унышы белән котлап, киләчәктә бар теләкләренен тормышка ашуын тели.
Бvген “Пенза олкәсенен татар милли-мәдәни автономиясе” әгъзасы, “Россия 1 – Пенза” хәбәрләрен алып баручысы Альбина Медведева 11 яшькә кадәр бию белән шогыльләнгән. ПГУнын тарих-филология магистранты әдәбият һәм психология белән кызыксына, татар халык ашларын пешерергә ярата, буш вакытларында модель, стилист-визажист булып та эшли. Жинvчегә Lada Granta машинасы ачкычларын Васил Шәйхразыев тапшырган.
- ...Бу хыялны тормышка ашыручы Ходаема, әти-әниемә бик рәхмәтле. Оештыручыларга, кызларга, сенелләремә, иганәчеләргә безгә шундый зур әкиятне кvрсәтvләре очен бик зур рәхмәт. Бу чыннан да искиткеч мизгелләр. Минем



кvнелем, кочем туган телемдә, туган жиремдә, халкымда. Татарлыгым белән мин бик горурланам. Бик зур рәхмәт, – дигән интервьюсынын берсендә жинvче Альбина Медведева.
Шулай ук Ботендонья татар конгрессы Башкарма комитеты житәкчесе Данис Шакиров торле номинациядә жинvчеләрне бvләкләгән: «Ин ягымлы кыз» – Аделина Гайнетдинова (Торкия); «Ин зур ачыш» – Диана Морәхмәдова (Кыргызстан Республикасы); «Ин зыялы кыз» – Айгол Котдусова (Татарстан Республикасы); «Ин унган кыз» – Зәринә Гомәрова (Оренбург олкәсе); «Ин ихлас кыз» – Эльназ Жамалетдинова (Чуашстан Республикасы); «Ин зирәк кыз» – Назлыгол Минһажева (Алмания); «Ин максатчан кыз» – Динә Абдуллина (Мәскәv шәһәре); «Ин ялкынлы кыз» – Илсинә Хатыбжанова (Пермь крае); «Ин монлы кыз» – Алсу Идрисова (Томск олкәсе); «Ин тырыш кыз» – Әлфия Фагаманова

(Башкортстан Республикасы); «Ин ижади кыз» – Камилә Байбәкова (Үзбәкстан Республикасы); «Ин наз-лы кыз» – Галия Палютина (Ростов олкәсе); «Ин нәзәкатьле кыз» – Альбина Медведева (Пенза олкәсе).
Әлеге конкурс сонгы тапкыр 2019нчы елда vткәрелгән. Короновирус пандемиясе вакытында уздырылмый торган. Бу - матурлык кvрсәтv мәйданчыгы гына тvгел, ә туган телне, милли гореф-гадәтләрне саклап калу һәм аларны доньяга таныту момкинлеге дә, ди оештыручылар. Шундый эчтәлекле, грандиоз чаралардан сон бераз боегып калабыз: Мордовия татарларыбыз кайда сон? Әллә татарларыбызда горурланып катнашучыбыз юкмыни? Ә бит Мордовия “Татар кызы” билгеләгән иде, Мордовиядә жинvче булып, Ташкентта катнашучылар белән бергә, полуфиналга да Алина Ямбикова чыкты.
Быел Халыкара “Татар кызы-2023” исеменә Пенза олкәсеннән Альбина Медведева лаек булды! Димәк, киләсе елда Пенза шәһәрендә очрашканга кадәр.

**Наилә НАСЫРОВА**